**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» гыйнвар 2022г. с. Тюлячи № 287

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы халкы өчен 2023 елның 1 гыйнварыннан торак-коммуналь хезмәтләргә тарифларны раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы «Хезмәт күрсәткәндә һәм күпфатирлы йортта гомуми мөлкәт тиешле сыйфатта карап тоту һәм ремонтлау буенча эшләр башкарганда һәм (яки) билгеләнгән вакыттан артып киткән тәнәфесләр булган очракта күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту кагыйдәләрен һәм торак бинаны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында», Татарстан Республикасы Президентының 2022 елның 26 ноябрендәге УП-832 номерлы «2022 елның декабренә һәм 2023 елга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә кертелә торган түләүне үзгәртүнең иң чик (максималь) индекслары турында» Указы, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауга минималь кертем күләмен билгеләү турында» 2013 елның 29 ноябрендәге 450 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 28 ноябрендәге 506 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елның 1 гыйнварыннан түбәндәгеләрне расларга һәм гамәлгә кертергә:

- социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен торак урынны карап тоткан һәм ремонтлаган өчен түләү күләме һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән милекчеләр өчен торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләме, 1 номерлы кушымта нигезендә;

- район халкы өчен коммуналь хезмәтләргә тарифлар, 2 номерлы кушымта нигезендә.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Ф.С. Вәлеев

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«27» 12 2022 № 287
карарына 1 номерлы кушымта

2023 елга район халкы өчен торак хезмәтләренә тарифлар

| Хезмәтнең атамасы | Үлчәү берәмлеге | Гамәлдә булу вакыты 01.01.2023ел - 31.12.2023 ел кадәр (сум.) |
|---|---|---|
| 1. Торак фонды белән идарә итү | $м^2$ | 4,28 |
| 2. Торак бинага агымдагы ремонт | $м^2$ | 4,14 |
| 3. Йорт эчендәге сантехника челтәрләрен агымдагы ремонтлау | $м^2$ | 2,75 |
| 4. Газүткәргечнең йорт эчендәге челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | $м^2$ | 0,42 |
| 5. Электр белән тәэмин итүнең йорт эчендәге челтәрләрен агымдагы ремонтлау | $м^2$ | 1,56 |
| 6. Су белән тәэмин итүнең гомумйорт системаларын агымдагы ремонтлау | $м^2$ | 0,62 |
| 7. Йорт яны территориясен җыештыру | $м^2$ | 4,51 |
| 8. Дератизация | $м^2$ | 0,15 |

Сыек көнкүреш калдыкларын чыгару буенча хезмәт күрсәтүнең күпфатирлы йортлар өчен тәкъдим ителә торган бәясе: 1.01.2023 елдан 31.12.2023 елга кадәр - 159,03 сум/ай.

Эшләр белән идарә итүче И.Т. Һадиев

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«__» _______ 2022 № ____
карарына 2 номерлы кушымта

2023 елга район халкы өчен коммуналь хезмәтләргә тарифлар

| Хезмәтнең атамасы | Үлчәү берәмлеге | Гамәлдә булу вакыты 01.01.2023ел - 31.12.2023 ел кадәр (сум.) |
|---|---|---|
| Халык өчен | | |
| 1. Бер юынуга мунча хезмәтләре күрсәтү | кеше | 100 |

Эшләр белән идарә итүче — И.Т. Һадиев